**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^4$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 433-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^4$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 433-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2185-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кетрелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Экология кодексының 135$^4$ статьясына үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 135$^4$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 нче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге нормативларга аучылык ресурсларын рөхсәт ителгән алу нормативлары, биотехник гамәлләр нормативлары, шулай ук аучылык җирләре чикләрендә аерым аучылык ресурсларының минималь санын урнаштыру таләпләре керә.»;

2) 4 нче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге нормативлар федераль закон нигезендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^4$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^4$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проекты «Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясына ярашлы рәвештә эшләнгән.

Күрсәтелгән Федераль законның 38 статьясына аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге нормативларга аучылык ресурсларын алуга рөхсәт ителгән нормативларны, биотехник чаралар нормативларын, шулай ук аучылык җирләре чикләрендә аучылык ресурсларының аерым төрләренең минималь санын урнаштыруга таләпләрне кертү өлешендә үзгәрешләр кертелде. Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^4$ статьясына ачыклаучы үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^4$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^4$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^4$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^4$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.